СОВЕТ
ПЕТРОПАВЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 33
с.Слобода Петропавловская,423198

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ПЕТРОПАВЕЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ленин урамы, 33
Петропавловка бистәсе авылы ,423198

тел.: (8-4348) 3-35-41, факс: (8-4348) 3-35-18.Ppav.Nsm@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Петропавел авыл җирлеге советы утырышы**
**КАРАРЫ**

**« 14» нче ноябрь 2018 ел** **№ 41-114**

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы һәм гражданнарның үзара салымы акчаларын файдалану турындагы нигезләмәне раслау хакында**

2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ нче номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән 23-ТРЗ нче номерлы «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законы, 2013 елның 22 ноябрендә кабул ителгән «Гражданнарга үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетының башка бюджетара трансфертларын бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 909 нчы номерлы карары, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Петропавел авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлеге Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТӘ:**

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчасы белән файдалану һәм гражданнарның үзара салымы турындагы теркәлгән нигезләмәне расларга
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталының «Интернет» мәгълүмати - телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan. ru., Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).
3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлеге Советының 2017 елның 8 ноябрендәге 31-87 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлеге

территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында " карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлеге Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Петропавел авыл
җирлеге башлыгы Д.С.Никитин

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Петропавел авыл
җирлеге Советы карарына кушымта
2018 елның 14 ноябрь № 41-114

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым һәм гражданнарның үзара салым акчаларын куллану турында**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлеге территориясендә (алга таба - авыл җирлеге) үзара салым тәртибендә җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен халыкның өстәмә чараларын җәлеп итү һәм алардан файдалану тәртибен җайга сала.
2.1. Гражданнар - яшәү урыны җирлек чикләрендә урнашкан Россия Федерациясе гражданнары.
Гражданнарның үзара салым акчалары дип җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен гражданнарның бер тапкыр түләүләре аңлатыла.
Гражданнарның үзара салым мәсьәләсе буенча җирле референдум (гражданнар җыены) – гамәлдәге законнар, Җирлек Уставы нигезендә үткәрелә торган референдум (гражданнар җыены), яшәү урыны буенча җирлек чикләрендә теркәлгән референдумда (җыеннарда) катнашу хокукына ия булган Россия Федерациясе гражданнарының үзара салым мәсьәләсе буенча яшерен тавыш биргәндә тигез һәм турыдан-туры белдерүләре нигезендә җирле референдум (гражданнар җыены).

2. Гражданнарның үзара салым мәсьәләсе буенча
референдум үткәрүне тәкъдим итү (гражданнар җыены)

2.1. Гражданнарның бер тапкыр түләүләрен кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда, ә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турындагы» Федераль законының 251 маддәсе 1 өлешенең 4 һәм 41 пунктларында каралган очракларда гражданнар җыенында хәл ителә.
2.2. Гражданнарның үзара салымы мәсьәләсе буенча җирле референдумны (гражданнар җыенын) үткәрү инициативасы белән чыгучылар:
- җирле референдумда катнашу хокукына ия булган Россия Федерациясе гражданнары;
- сайлау берләшмәсе, уставында сайлауларда һәм (яки) референдумнарда катнашуны күздә тоткан һәм федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта теркәлгән иҗтимагый берләшмәләр;
- Бергәләп тәкъдим иткән Җирлек Советына һәм Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесенә.

3. Референдум билгеләү, әзерләү һәм үткәрү

3.1. Җирле референдум билгеләү турындагы карар Җирлек Советына җирле референдумнар билгели торган документлар кергән көннән соң 30 көн эчендә Җирлек Советы тарафыннан кабул ителә.

3.2. Инициативалы төркем тарафыннан тәкъдим ителгән гражданнар җыены Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлеге Советы карары белән, ә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлеге башлыгы инициативасы белән 30 көн эчендә барлык кирәкле документлар кергән көннән соң Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлеге башлыгы карары белән билгеләнә.
3.3. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдумда тавыш бирү көне - ноябрьнең өченче якшәмбесе.
Әгәр җирле референдум билгеләнергә тиешле ноябрьнең өченче якшәмбесе эшләми торган бәйрәм көненә яки аннан алдагы көнгә туры килә икән, яки ноябрьнең өченче якшәмбесе билгеләнгән тәртиптә эш көне дип игълан ителгән булса, референдум ноябрьнең дүртенче якшәмбесенә билгеләнә.
4.4. Җирле референдумны әзерләү һәм үткәрү тәртибе 2004 елның 24 мартында кабул ителгән «Җирле референдум турында» 23-ТРЗ нче номерлы Татарстан Республикасы Законы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ нче номерлы Татарстан Республикасы Законы белән җайга салына.
4.4. Җирле референдум әзерләү һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны финанслау Җирлек бюджеты хисабына башкарыла.

## 4. Җирле референдум (халык җыены) карары

4.1. Гражданнарның үзара салымы җирле референдумда кабул ителгән карар буенча Җирлек территориясендә тотыла.
4.2. Референдум үзара салым буенча түләүләр күләмен һәм җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне раслый, җыелган акчалар аларны хәл итүгә тотыла. Үзара салым күләме, гражданнарның аерым категорияләреннән тыш, Җирлекнең барлык гражданнары өчен дә тигез күләмдә билгеләнә.
4.3. Тавыш бирү нәтиҗәләрен һәм җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru. мәҗбүри рәвештә бастырырга (халыкка игълан итәргә).
Җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) мизгелдән үз көченә керә.
4.4. Референдум (гражданнар җыены) турында карар Җирлекнең барлык гражданнары өчен дә мәҗбүри булып тора.

## 5. Үзара салым акчаларын җыю тәртибе

5.1.Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән раслана (2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ нче номерлы Федераль законның 45 маддәсе, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән «Җирле референдум турында» 23-ТРЗ нче номерлы Татарстан Республикасы законының 60 маддәсе)

## 6. Үзара салым акчаларын кулану

6.1. Үзара салым тәртибендә җыелган һәм җирлек бюджетына кергән акчалар җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән карарда каралган җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне (конкрет мәсьәләне) хәл итүгә Җирлек Башкарма комитеты тарафыннан тотыла.

6.2. Авыл җирлеге Башкарма комитеты референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән карар үз көченә кергәннән соң көннән бер көн эчендә референдум карарын тормышка ашыру максатыннан чаралар планын раслый.

6.3. Хисап елында файдаланылмаган акчалар киләсе финанс елына күчә һәм референдум карары (гражданнар җыены) белән каралган максатларга тотыла.

6.4. Авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе елга бер тапкыр авыл җирлегендә яшәүчеләр алдында җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән карарның үтәлеше турында хисап тота.

6.5. Авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең әлеге Нигезләмәнең 6.4 пункты нигезендә әзерләнгән хисаплары Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru , Яңа Чишмә районы, Петропавел авылы, Ленин урамы (34 нче йорт янында), Андреевка авылы, Үзәк урамы, 5 йорт адресы буенча урнашкан Петропавел авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы һәм башка ысул белән халыкка җиткерелә.

6.6. Авыл җирлеге Башкарма комитеты гражданнарның үзара салым акчаларын исәпләү, тулы күләмдә һәм вакытында түләүне контрольдә тота.

## 7. Әлеге Нигезләмәне бозган өчен җаваплылык

7.1. Гражданнарның билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелергә тиеш.

7.2. Акчаларның максатчан кулланылышын контрольдә тоту Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Контроль-хисап палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.